Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советы

# КАРАРЫ

11 май 2018 ел №118

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 17 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының "Әлмәт шәһәре" муниципаль берәмлегендә халык дружинасы турындагы нигезләмә турында»гы 160 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2017 елның 31 декабрендәге «Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 497-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, җәмәгать тәртибен саклау өлкәсендә хокукый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә, хокукый мониторинг тәртибендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 17 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының “Әлмәт шәһәре” муниципаль берәмлегендә халык дружинасы турындагы Нигезләмә хакында” 160 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар кушымтасындагы “Халык дружинасына кабул итү һәм аңардан чыгару” 5 нче бүлегенең 5.2 пунктының 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

8) халык дружинасына кабул итү көненә кадәрге ел дәвамында берничә тапкыр суд тәртибендә белә торып административ хокук бозулар өчен административ җәзага дучар ителгән;

2. Район башкарма комитеты хокук идарәсе башлыгына (Шәйхулова Ф.Х.) әлеге карарны “Альметьевский вестник” газетасында бастырып чыгарырга, “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU ) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә (Н.А.Бочкарев ) йөкләргә.

Шәһәр башлыгы А.Р. Хәйруллин